ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700**

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **К А Р А Р**

__ _30.09.2025______________ **№ 747______**

## Биектау муниципаль районында гражданнарны социаль ипотека программасы буенча торак урыннар сатып алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗлар дип тану тәртибен һәм шартларын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру һәм республика дәүләт ярдәме кысаларында торак бирү тәртибен камилләштерү чаралары турында» 2007 елның 02 августындагы 366 номерлы карарын гамәлгә ашыру, торак шартларын яхшыртуда гражданнарга өстәмә ярдәм күрсәтү максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районында гражданнарны социаль ипотека программасы буенча торак урыннар сатып алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗлар дип тану тәртибен һәм шартларын 1 нче кушымта нигезендә расларга.
2. Биектау муниципаль районының кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ яшәүчеләренә торак урыннары бирү «кичектергесез ярдәм» квотасы кысаларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 02 августындагы 366 номерлы карары белән расланган Социаль ипотека буенча гражданнарга торак урыннары бирү тәртибенең 2 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.
3. Әлеге карарны интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча игълан итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы

Башкарма комитетының торакны исәпкә алу һәм бүлү бүлеге башлыгына йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф.Хәкимуллин

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитетының 2024
елның «30» 09.2025 747
номерлы карарына 1 нче
кушымта

**Биектау муниципаль районында гражданнарны социаль ипотека программасы буенча торак урыннар сатып алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗлар дип тану тәртибе һәм шартлары**

1. Биектау муниципаль районында гражданнарны социаль ипотека программасы буенча торак урыннар сатып алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗлар дип тану тәртибе һәм шартлары (алга таба – Тәртип) Биектау муниципаль районында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбендә торучы гражданнарга социаль ипотека программасы буенча торак сатып алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗлар дип тану хокукын һәм шартларын билгели (алга таба - хисап).

2. Әлеге Тәртиптә түбәндәге терминнар, билгеләмәләр, кыскартулар кулланыла:

- Исәпкә алу – социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу;
- Торак комиссиясе – социаль ипотека программасы кысаларында торак урыннарына мохтаҗлар буларак гражданнарны исәпкә кую мәсьәләләре буенча Биектау муниципаль районы торак комиссиясе;
- кандидатура - Биектау муниципаль районында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбенә алынган, әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә кандидатларның җыелма исемлегенә кертелгән гариза бирүче;
- Торак фонды - «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт торак фонды»;

3. Социаль ипотека программасы буенча торак сатып алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ дип гражданнарның (гаиләләрнең) түбәндәге категорияләре танылырга мөмкин:

3.1. Янгын, йорт ишелү, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу нәтиҗәсендә зыян күрүчеләр, шулай ук билгеләнгән

тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урында яшәүче гражданнар (гаиләләр);

3.2. инвалидлар, инвалид балалары булган гаиләләр;

3.3. сугышчан хәрәкәтләр ветераннары, хәрби хезмәт инвалидлары, һәлак булган (вафат булган) сугыш хәрәкәтләре ветераннары, хәрби хезмәт инвалидлары гаиләләре;

3.4. күпбалалы гаиләләр;

3.5. дини оешмалар хезмәткәрләре;

3.6. авыр тормыш хәленә тарыган, шуның нәтиҗәсендә тораксыз калган һәм хәзерге вакытта вакытлыча торак урынында яшәүче гражданнар;

3.7. Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбендә торучы гражданнар (гаиләләр), - 2005 елның 01 мартына кадәр торак урыннарына мохтаҗлар буларак яшәү урыны буенча исәпкә алынган гражданнар; Россия Федерациясе Торак кодексының 57 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән гражданнардан тыш, социаль наем шартнамәләре һәм социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондыннан торак урыннары бирелүгә мохтаҗ дип танылган гражданнар.

4. Әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән категорияләргә караган гражданнарны Социаль ипотека программасы буенча торак сатып алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ дип тану түбәндәге тәртиптә гамәлгә ашырыла:

4.1. исәптә торучы гражданнар аларны Социаль ипотека программасы буенча торак урын сатып алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗлар дип тану турында гариза белән исәпкә кую урыны буенча Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына мөрәҗәгать итәләр;

4.2. исәптә тормаган гражданнар Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына теркәү урыны буенча аларны Социаль ипотека программасы буенча торак урын сатып алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ дип тану турында гариза белән, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 190 номерлы карары нигезендә исәпкә кую турында гариза һәм документлар белән мөрәҗәгать итәләр. Исәпкә кую Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 190 номерлы карары нигезендә гамәлгә ашырыла;

4.3. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетында (алга таба - Башкарма комитет) әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә кандидатураларның җыелма исемлекләре төзелә;

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 15 апрелендәге 190 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны

исәпкә кую кагыйдәләре һәм тәртибенең 15 пунктын үтәү максатларында, Социаль ипотека программасы буенча торак урыннар сатып алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ Биектау муниципаль районында яшәүчеләрнең исемлекләре Торак фондына кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ гражданнарны Татарстан Республикасы буенча Гаилә реестрына кертү турында карар кабул итү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 02 августындагы 366 номерлы карары нигезендә торак урыннары бирү өчен җибәрелә;

6. Торак комиссиясе кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ дип танылган гаиләләр исемлекләренә үзгәрешләр кертергә мөмкин, әгәр мөрәҗәгать итүче:

- кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ гражданнар өчен квотага кергәнче фатир сайласа;

- торак сатып алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ дип танылган гаиләләр исемлегеннән чыгару турында гариза биргән булса;

- әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән гражданнар категорияләренә кертү өчен нигезне югалткан булса;

- исәптән төшерелгән булса.